**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы**
**рус теле комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе турында» 2022 елның 20 маендагы ПУ-355 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 мартындагы 152 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.А. Кондратьеваны, З.В. Редьконы, В.П. Юдинны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Вәлиева Гөлшат Фән кызын – «Бәхетле язмышлар» хәйрия фонды директорын ((килешү буенча);

Мостафина Софья Альфред кызын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасарын;

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.А. Александровскаяның – «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Казан шәһәре Совет районының «А.С. Пушкин исемендәге 93 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Л.Е. Бушканецның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры, Россия фәннәр академиясе Дөнья мәдәнияте тарихы советының Чехов комиссиясе әгъзасы (килешү буенча)»;

Е.Г. Гущинаның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институты Халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөнья тарихы югары мәктәбенең Татарстан тарихы, антропология һәм этнография кафедрасы доценты (килешү буенча)»;

И.В. Ерофееваның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры, Татарстан Республикасында рус теле буенча «Тоталь диктант» халыкара мәгърифәти акциясенең Казан шәһәре рус теле укытучылары эксперт советы җитәкчесе (килешү буенча)»;

Р.Ф. Мөхәммәтшинаның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбе деканы, Россия рус теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе идарәсе әгъзасы, Халыкара рус теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе әгъзасы (килешү буенча)»;

А.Н. Пашкуровның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры (килешү буенча)»;

Т.А. Титованың – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институты Халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөнья тарихы югары мәктәбенең Татарстан тарихы, антропология һәм этнография кафедрасы профессоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 28 ноябрь
№ 814